ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 45 от «03» 02 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 13 гыйнварындагы «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 4 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль законнарны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 13 гыйнварындагы «Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 4 нче номерлы карарына(алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Карарның нигезләмәсенә түбәндәге эчтәлектәге 2.5.5, 2.5.6, 2.5.7 пунктларын өстәргә:

"2.5.5. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче булып торучы балигъ булмаганның законлы вәкиле алганда, балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы

000001255

документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләрен алу хокукын гамәлгә ашыру мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиле тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин. Бу очракта балигъ булмаганның законлы вәкиле булган мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганның балигъ булмаганга карата тиешле хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алуга вәкаләтле башка законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләрне күрсәтә.

2.5.6. Балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаганга карата муниципаль хезмәт күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә бирелми.

2.5.7. Балигъ булмаганга карата кәгазьдә язылган документ рәвешендә рәсмиләштерелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен, шул исәптән аларны бирү ысуллары һәм сроклары мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаганның законлы вәкиленә күрсәтү тәртибе, әлеге бүлекнең 2.5.6 пунктында каралган таләпне исәпкә алып, әлеге Регламентның 3.6.3.1-3.6.3.3 пунктларында билгеләнә..".

2. Әлеге карарны өч эш көне эчендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru// рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен коннтрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М.Ефимовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Гарипов